**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**30 май 2019 ел** **№ 301**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партияләрдән кала) белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эшкә алучыдан (эш бирүчедән) рөхсәт алу тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында", 2007 ел, 2 нче март, 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы 1 бүлеге 3 пункты, "Ришвәткә каршы тору", 2008 ел, 28 нче декабрь, 273-ФЗ номерлы Федераль закон, "Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында", 2017 ел, 29 нчы июль, 217-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының 2017 ел, 13 нче октябрь, 162 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партияләрдән кала) белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә эшкә алучыдан (эш бирүчедән) рөхсәт алу тәртибе турында Нигезләмәнең 1 пунктына түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

«1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан түләүсез нигездә аерым коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга эшкә алучыдан (эш бирүчедән) рөхсәт алу тәртибе турында әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә), "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында", 2007 ел, 2 нче март, 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы 1 бүлеге 3 пункты нигезендә эшләп чыгарылган (алга таба – Федераль закон), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан шәхсән үзе яки ышанып тапшырган затлар аркылы эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнү, коммерцияле оешма идарәсендә яки коммерцияле булмаган оешма идарәсендә катнашу (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан кала); түләүсез нигездә һөнәри союз идарә органында, шул исәптән, җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау

комиссиясе аппаратында оештырылган сайланган беренчел профсоюз органында катнашу; съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешма, торак, торак төзелеше, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәчелек, дача куллану кооперативы, милек хуҗалары ширкәте гомуми җыелышында катнашу; күрсәтелгән коммерцияле булмаган оешмалар белән (сәяси партиядән һәм профсоюз органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында оештырылган беренчел профсоюз оешмасының сайлап куелган органыннан, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратыннан тыш) бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында яки эшкә алучы (эш бирүче) рөхсәте белән аларның идарә итү коллегиаль органнары составына керү, муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә), учредителе (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә итү органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлекнең мәнфәгатьләрен чагылдырудан тыш, муниципаль берәмлек исеменнән оешма учредителе вәкаләтләрен башкару яки муниципаль милек булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлеше) белән идарә итүне билгеләүче муниципаль хокукый актларына нигезләнеп; федераль законнар белән каралган башка очракларда түләүсез идарә итүдә катнашу өчен рөхсәт алу процедурасын регламентлаштыра;.».

2. Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарына бердәй норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы һәм Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

Совет Рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин